**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены карары**

21.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Татар Буасы авылында юлларны ремонтлау, зиратны төзекләндергә (инвентарь алуга), спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерүгә (инвентарь алу), кышкы чорда юлларны карап тотуга, җәйге вакытта территорияне чабуга (ягулык-майлау материаллары сатып алуга, килешү буенча хезмәт һәм хезмәтләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Буасы авыл җирлеге башлыгы _________ Р.Ф.Йосыпов

Гражданнар җыены секретаре _________ Р.М. Җамалетдинова